КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 1 август г.Казань № 744

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 декабрь, 1157 нче, 2021 ел, 19 февраль, 88 нче, 2021 ел, 08 декабрь, 1205 нче, 2022 ел, 14 февраль, 128 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы

территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булу.»;

2.3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциягә карамаган  оешманың бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә субсидия бирү каралган елда Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын, шулай ук экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазен;»;

3.9 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы;»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

«Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә

ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

5.2 пунктта «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга;

5.6 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы бишенче, унҗиденче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Тәртипнең 2.3 пунктындагы унынчы абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин